РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ НИЖНЕКАМСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423586, г. Нижнекамск, пр. Строителей, 12
тел./факс (8555) 41-70-00

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТҮБӘН КАМА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

423586, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
тел./факс (8555) 41-70-00

РЕШЕНИЕ КАРАР

№ 32 2022 елның 1 июне

**Түбән Кама муниципаль районы Советының
2017 елның 7 июлендәге 37 номерлы «Хуҗалык җәмгыятьләрен төзегәндә, үзгәртеп корганда һәм гамәлдән чыгарганда, җирле үзидарә органнарының үзара хезмәттәшлеге тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында»
карарына үзгәрешләр кертү турында**

2022 елның 16 апрелендә кабул ителгән 114-ФЗ номерлы «Акционерлык җәмгыятьләре турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. «Түбән Кама муниципаль районы Советының 2017 елның 7 июлендәге 37 номерлы «Хуҗалык җәмгыятьләрен төзегәндә, үзгәртеп корганда һәм гамәлдән чыгарганда, җирле үзидарә органнарының үзара хезмәттәшлеге тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарга кушымтада

1.1. 1.7.1. пунктында «Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының икътисадый фаразлау, транспорт һәм элемтә бүлеге» сүзләрен «Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының икътисадый үсеш һәм эшкуарлыкка ярдәм итү идарәсе» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 1.7.2. пунктында «2.1.1 яки 3.1.1 пунктчасы нигезендә» сүзләрен «2.1.1 яки 4.1.1 пунктчасы нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. 4.1.2 пунктында «1.6.2 пункты нигезендә» сүзләрен «1.7.2 пункты нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

1.4. 4.3.1 пунктының «в» пунктчасында «Россия Федерациясе Салымнар һәм җыемнар министрлыгының тиешле территориаль инспекциясе штампы белән» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.5. 4.4.1. пунктының «а» пунктчасында «Россия Федерациясе Салым һәм җыемнар министрлыгының территориаль инспекциясе» сүзләрен «Федераль салым хезмәте инспекциясе» сүзләренә алмаштырырга;

1.6 4.4.6 пунктында «Россия Федерациясе Салым һәм җыемнар министрлыгының территориаль органы» сүзләрен «Федераль салым хезмәтенең тиешле инспекциясе» сүзләренә алмаштырырга;

1.7 4.4.7 пунктында «Россия Федерациясе Салым һәм җыемнар министрлыгының территориаль органы» сүзләрен «Федераль салым хезмәтенең тиешле инспекциясенә» сүзләренә алмаштырырга;

1.8 4.4.9 пунктында «3.4.10 пункты» сүзләрен «4.4.10 пункты» сүзләренә алмаштырырга;

хуҗалык җәмгыятьләрен төзегәндә, үзгәртеп корганда һәм гамәлдән чыгарганда, җирле үзидарә органнарының үзара хезмәттәшлеге тәртибе турында нигезләмәнең 1 нче кушымтасында:

1.9 6.1 пунктының 3 абзацында «бухгалтерлык кенәгәләре» сүзләрен «бухгалтерлык исәбе документлары» сүзләренә алмаштырырга;

хуҗалык җәмгыятьләрен төзегәндә, үзгәртеп корганда һәм гамәлдән чыгарганда, җирле үзидарә органнарының үзара хезмәттәшлеге тәртибе турында нигезләмәнең 2 нче кушымтасында:

1.10 4.2 пунктның 3 абзацында «бухгалтерлык кенәгәләре» сүзләрен «бухгалтерлык исәбе документлары» сүзләренә алмаштырырга;

1.11 5.7.1 пунктының 2 абзацында «бухгалтерлык хисаплылыгы» сүзләрен «бухгалтерлык (финанс) хисабы» сүзләренә алмаштырырга;

1.12 8.3. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «8.3 Җәмгыятьтә катнашучыларның гомуми җыелышының компетенциясе «Җаваплылыгы чикләнгән ширкәтләр турында» 1998 елның 8 февралендәге 14-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә җәмгыять уставы белән билгеләнә»;

1.13 9.4 пунктының 4 абзацында «бухгалтерлык баланслары» сүзләрен «еллык бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгы» сүзләренә алмаштырырга;

1.14 11.1. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «11.1 Җәмгыять турында мәгълүмат аларга «Җаваплылыгы чикләнгән ширкәтләр турында» 1998 елның 8 февралендәге 14-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Россия Федерациясенең башка хокукый актлары таләпләре нигезендә бирелә.»

1.15 8.5 пунктының 2 абзацын, 8.6 пунктының 9 абзацын, 11.2-11.4 пунктларын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карар, әлеге карарның 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 1.9, 1.11, 1.14 пунктларыннан тыш, рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Түбән Кама муниципаль районы Уставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны социаль-икътисади үсеш, бюджет-финанс мәсьәләләре һәм муниципаль милек буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама муниципаль районы Башлыгы
вазыйфаларын башкаручы,
Башлык урынбасары

ПРЕДСТАВИТЕЛЬНЫЙ ОРГАН
ВӘКИЛЛЕКЛЕ ОРГАН

А.В.Умников